# БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘПТӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ

, Әтнә муниципаль районы Күәм урта гомуми белем бирү мәктәбенең 1 кв. категорияле башлангыч сыйныф укытучысы Бурганова Р.Н.

2011 ел.

**Проектлар методы – укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән укыту системасы ул. Ул мәктәптә укытучы җитәкчелегендә эшләнә торган мөстәкыйль иҗади эш.**

**Проект эшчәнлеге – төпле фикере булган балалар тәрбияләү технологияләреннән берсе.**

**Проект эшчәнлегенең нигезе- тикшеренү эше.**

**Максаты: укучыларның шәхси үсешенә, уңышлы аралашуларына ирешү, аларны һәртөрле эшчәнлеккә иҗади якын килергә өйрәтү.**

# Проектлы белем бирүгә

1.Белемнәрне проект рәвешендә үзләштерү.

2.Элекеге проектларны файдалану.

3.Яңа проектлар рәвешендә яңа белемнәрне булдыру.

Проект эшчәнлеге укучыларда да, укытучыда да зур кызыксыну тудыра. Ул фикерләүне, сөйләмне, үз уйларыңны формалаштыра белү сәләтен үстерә. Проект эшчәнлеге барышында укучы коллективта эшләргә, үзенә бирелгән эшкә җаваплы карарга, куелган сорауларга җавап табарга өйрәнә.

Башлангыч сыйныф укучысы өчен проект эшчәнлеге шактый катлаулы. Ләкин укучылар белән барлык фәннәр буенча да проект эшчәнлеге оештырырга мөмкин.Ә иң беренче проектның проблемасы яки идея барлыкка килергә тиеш.

**Проект эшчәнлеге түбәндәге этаплардан тора.**

1. Темасын уйлап табу.
2. Планлаштыру.
3. Максатын һәм бурычларын билгеләү.
4. Тикшеренү, эзләнү.
5. Проектны яклау.
6. Проект эшенең күрсәткече.(презентация)
7. Бәяләү.

# Проект эшчәнлеген ничек оештырырга соң?

**Эшнең уңышлы килеп чыгуы аның дөрес оештырылуына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле.**

укытуч
ы

укуч
ы

ата-
ана

**укытучы**

**Киңәшче**
**юнәлеш бирүче**
**төзәтмәләр кертүче**
**рухландыручы**
**илһам өстәүче**



# укучы



Эзләнүче, идеяне тормышка ашыручы
мәгълүмат җыючы, фикерләүче
күзәтүләр нигезендә модель төзүче
барлыкка килгән нәтиҗәләрне анализлаучы
тәҗрибәләр үткәрүче, интернет материалларын
кулланучы проектны яклаучы.





# ата-ана

**Укучыга кирәкле мәгълүматне**
**табарга ярдәм итүче**
**идеяләрне тулыландыручы**
**иҗади бала белән бергә**
**кызыксынучы**
**бала белән көндәлек**
**аралашучы ролен үти.**

**Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.**

## Балалар эшенең күрсәткече

1-4 классларда рәсем, инша,табышмак, шигырь, сүзлек һәм башкалар булырга мөмкин.

## Проек эшенең нәтиҗәсе

1-2 классларда мәгълүмат тупланган китап яисә альбом

3-4 классларда проект эше презентация, сценарий, фильм, каталог һ.б ярдәмендә башкарылырга мөмкин.

Укучыларга проект эшчәнлегенә йомгак ясаганда

***1.Проект эшендә нәрсә кызыклы булды?***

***2.Аеруча нәрсә ошады?***

***3.Нинди яңалыклар белдең?***

***4.Бу теманы өйрәнүне дәвам итәр идеңме?***

***5.Киләчәктә нинди проект эшен дәвам итәр идең?*** -кебек сораулар бирергә була.

**Проект эшчәнлеге укытучы һәм укучыдан зур түземлек, сабырлык, күп вакыт сарыф итүне сорый.Тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен, эш барышында әдәби китаплардан, сүзлекләрдән, интернет аша күп мәгълүмат тупларга, иҗади фикер йөртергә кирәк. Гомумән, проект методы - баланың интеллектын, иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә, кызыксынучанлыгын арттыруда нәтиҗәле алымнарның берсе.**